РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» март 2020г. г. Альметьевск № 363

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы ТР Законына үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә, ТР Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә, 2019 елның 8 ноябрендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләрен исәпкә алып, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 09.08.2019 елгы 836п санлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 116 санлы карары белән расланган ТР Әлмәт муниципаль районы Уставына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 21 июнендәге 202 санлы, 2013 елның 4 июлендәге 305 санлы, 2014 елның 2 октябрендәге 398 санлы, 2015 елның 13 мартындагы 450 санлы, 2016 елның 29 апрелендәге 51 санлы, 2016 елның 28 декабрендәге 142 санлы, 2017 елның 27 июлендәге 188 санлы, 2018 елның 11 маендагы 237 санлы, 2019 елның 25 мартындагы 282 санлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юлларга.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне, теркәгәннән соң, «Альметьевский вестник» һәм «Әлмәт таңнары» газеталарында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы

Зак. № 3775

Федераль законның 44 нче маддәсе 8 нче өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне ТР Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары А.А. Зиминга йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль
районы Советының
2020 елның 12 мартындагы
363 санлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр

1. 6 нчы маддәнең 1 нче өлеше 13 нче пунктын «, авыл-ара территориядә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү;» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2. 6.1 маддәсенең 1 нче өлешен:

2.1. түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.1) «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итүнең төгәл бәяле зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча чараларның үтәлүенә муниципаль контрольне тормышка ашыру;»;

2.2. 12 нче пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

12) авыл җирлекләре генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләре генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рехсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр тезелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), авыл җирлекләре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рехсәт бирү, авыл җирлекләрен шәһәр тезелеше проектлавының җирле нормативларын раслау, авыл җирлекләре чикләрендә җирләрне резервлау һәм җир участокларын муниципаль ихтыяҗлар өчен алу, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру, РФ Шәһәр тезелеше кодексында күздә тотылган очракларда биналарны, корылмаларны карауны тормышка ашыру һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган хилафлыкларны бетерү турында рекомендацияләр бирү, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында уведомлениедә (алга таба – планлаштырылган тезелеш турындагы уведомление) күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган параметрлары һәм җир участогында индивидуаль торак тезелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге, индивидуаль торак тезелеше яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган тезү турында уведомлениедә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) җир участогында индивидуаль торак тезелеше объектын яки бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында уведомление, җир участокларында тезелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яки туры килмәве, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир участогын тартып алу хакында карар кабул итү турында уведомлениеләр юллау, РФ Шәһәр тезелеше кодексында каралган очракларда үз белдеге белән төзелгән

корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү, авылара территориядә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү;

3. 26 нчы маддәдә:

3.1. 2 нче өлешне түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«2. Район Советы депутаты, кагыйдә буларак, даими булмаган нигездә эшли, депутатлык эшчәнлеген теп эш урыны буенча үз вазифаларын үтәү белән бергә алып бара. Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан 10 процентган артык булмаган өлеше генә даими нигездә эшли ала. Үз вәкаләтләрен даими нигездә тормышка ашыручы депутат, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затының түбәндәгеләргә хокукы юк:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү;

2) коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан кала:

а) бушлай нигездә сәяси партия, профессиональ союз, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасы сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-тезелеш, гараж кооперативлары, торак милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) ТР Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Президентына (Татарстан Республикасы дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан белдерү кәгазе белән бушлай нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси партия, профессиональ союз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, торак милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан кала;

в) бушлай нигездә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

г) муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен яки район исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен тормышка ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционер, катнашучы) район булган оешманың идарә итү һәм ревизия комиссиясе органнарында район мәнфәгатьләрен бушлай нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән кала. Шул ук вакытта, әгәр Россия Федерациясе халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) әгәр Россия Федерациясе халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, чит илләрнең коммерциячел булмаган, хөкүмәтнеке булмаган башка органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керү»;

3.2. 7 нче елешне түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«7. Район Советы депутаты, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы

Федераль закон, 03.12.2012 елгы 230-ФЗ санлы «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында»гы Федераль закон, 07.05.2013 елгы 79-ФЗ санлы «Затларның аерым категорияләренә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле кәгазьләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазифаларны башкарырга тиеш.»;

3.3. 9 нчы елештә «җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты» дигән сүзләрдән соң «яки әлеге затларга карата башка җаваплылык чаралары кулллану» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3.4. түбәндәге эчтәлектәге 9.1 өлеше белән тулыландырырга:

«9.1. Үз керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында дөрес һәм тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасын район Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифасыннан азат итү белән бергә аның вәкаләтләре срогы беткәнче район Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифа биләүдән мәхрүм итү;

3) вәкаләтләре срогы беткәнче аларны даими нигездә башкару хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вә- каләтләрне башкарудан азат итү;

4) вәкаләтләре срогы беткәнче район Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифа биләүне тыю;

5) вәкаләтләре срогы беткәнче даими нигездә вәка-ләтләр башкаруны тыю.»;

3.5. түбәндәге эчтәлектәге 9.2 өлеше белән тулыландырырга:

«9.2. Депутатка, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затына әлеге маддәнең 9.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

4. 35 нче маддәнең 6 нчы елешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«6. Депутат, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты, муниципаль вазифаны биләп торучы башка затның вәкаләтләре 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы «РФдә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

Депутат, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты, муниципаль вазифаны биләүче башка затның вәкаләтләре, 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон белән башкача күздә тотылмаганда, 25.12.2008 елгы 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль закон, 03.12.2012 елгы 230-ФЗ санлы «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында»гы Федераль закон, 07.05.2013 елгы 79-ФЗ санлы «Затларның аерым категорияләренә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле кәгазьләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, вазифаларны башкармаган очракта срогыннан алда туктатыла,»;

5. 38 нче маддәнең 2 нче өлешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«2. Район башлыгының түбәндәгеләргә хокукы юк:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү;

2) коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан кала:

а) бушлай нигездә сәяси партия, профессиональ союз, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасы сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, торак милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан белдерү кәгазе белән бушлай нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси партия, профессиональ союз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, торак милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан кала;

в) бушлай нигездә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

г) муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы елешләр) белән идарә итү тәртибен яки муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен тормышка ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен бушлай нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән кала. Бу вакытта, әгәр Россия Федерациясе халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) әгәр Россия Федерациясе халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, чит илләрнең коммерциячел булмаган, хөкүмәтнеке булмаган башка органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керү»;

6. 42 нче маддәнең 3 нче елешендә икенче җөмләне алып ташларга.

7. 44 нче маддәдә:

7.1. 1 нче өлештә:

7.1.1. 3 нче пунктның унөченче абзацын «, авылара территориядә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү;» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

7.1.2. 5 нче пунктның 8 нче абзацы кечен югалткан дип санарга;

7.1.3. 11 нче пунктның сигезенче абзацында «җирлек» сүзен «муниципаль район» дип алыштырырга;

7.2. 2 нче өлештә:

7.2.1. 1 нче пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«1) халыкка торак-коммуналь, транспорт, кенкүреш һәм башка хезмәтләр күрсәтү елкәсендә:

- авыл җирлекләре чикләрендә законда күздә тотылган тәртиптә электр, җылылык, газ белән тәэмин итүне оештыра;

- «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итүнең төгәл бәяле зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча чараларның үтәлүенә муниципаль контрольне тормышка ашыра;

- авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм эшләвен тәэмин итү, авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

- халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыра һәм авыл җирлекләре чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруны тәэмин итә;

- авыл җирлекләрендә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итә, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыра, торак төзелеше өчен шартлар тудыра, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне, авыл җирлекләре китапханәләренең китапханә фондлары сакланышын тәэмин итүне һәм туплауны оештыра;

- җирле традицион халык сәнгате иҗатын үстерү өчен шартлар тудыра, авыл җирлекләрендә халык сәнгате кәсепләрен саклап калу, яңарту һәм үстерүдә катнаша;»;

7.2.2. 3 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«- җирлек чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирә, төзелешкә рөхсәт бирү, авыл җирлекләре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирә;»;

7.2.3. 3 нче пунктның унберенче абзацында «Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдегең белән төзелгән корылманы сүтү, үз белдегең белән төзелгән корылманы сүтү яки аны җирдән файдалану һәм тезелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән рөхсәт ителгән тезелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрлары мәҗбүри таләпләренә туры китерү турында карарлар (алга таба - шулай ук билгеләнгән таләпләргә туры китерү)» дигән сүзләрне алып ташларга ;

8. 65.2 маддәсенең 1 нче өлеше 2 нче пунктын «, әгәр федераль законнар белән башкасы билгеләнмәсә» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

9. 87 нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 5 нче өлеш белән тулыландырырга:

«5. Район бюджетына башка муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә субсидияләр бирелергә мөмкин.»;

10. 88 нче маддәдә:

10.1. 1 нче елешнеӊ беренче абзацында «Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм бюджет хокук менәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар» дигән сүзләрне «бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, гаммәви норматив йөкләмәләрне һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләр буенча йөкләмәләрне бирә торган хокукый актлар нигезләмәләре, шулай ук бюджеттан акчалар бирү турында муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү» дигән сүзләр белән алыштырырга.

10.2. 2 нче өлештә «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» дигән сүзләрне алып ташларга.

10.3. 3 нче елешне түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«3. Эчке муниципаль финанс контроле район башкарма власте органы булып торучы муниципаль финанс контроле органының контроль эшчәнлеге булып тора».

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов